ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **К А Р А Р**

26.12.2024 | № 1158

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында 2025-2027 елларга Хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклауның озак сроклы территориаль программасын раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2008 елның 10 ноябрендәге 799 номерлы карарын үтәү йөзеннән, шулай ук хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлекне координацияләү, куркынычсыз хезмәт шартлары тудыру, җитештерүдә имгәнүләрне кисәтү, кешенең гомерен һәм сәламәтлеген саклау максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында 2025-2027 елларга Хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклауның озак сроклы территориаль программасын (алга таба – Программа) расларга.

2. Оешмалар, учреждениеләр, предприятиеләр җитәкчеләренә, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, әлеге Программаны гамәлгә ашыру чараларын күрергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф Хәкимуллин

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында 2025-2027 елларга Хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклауның озак сроклы территориаль программасы

## ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | Биектау муниципаль районында 2025-2027 елларга Хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклауның озак сроклы территориаль программасы (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2008 елның 10 ноябрендәге 799 номерлы карары; |
| Программаның заказчысы | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | Биектау муниципаль районы башкарма комитетының Хезмәтне саклау буенча координация советы; Биектау муниципаль районы предприятиеләре һәм оешмалары |
| Программаның максаты | Биектау муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләренең һөнәри куркынычларын киметү максатларында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту |
| Программаның бурычлары | 1. Хезмәтне саклау буенча дәүләт идарәсе системасын үстерү;<br>2. Укытуның заманча технологияләре нигезендә хезмәтне саклау хезмәткәрләрен өзлексез әзерләү;<br>3. Хезмәтне саклауны мәгълүмати тәэмин итү һәм пропагандалау. |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2025 - 2027 еллар |
| Программаны еллар буенча финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны Биектау муниципаль районы предприятиеләренең бюджеттан тыш акчалары исәбеннән финанслау күләме - 45000,0 мең сум, шул исәптән:<br>2025 ел – 15000,0 мең сум; |

| | |
|---|---|
| | 2026 ел – 15000,0 мең сум;<br>2027 ел – 15000,0 мең сум. |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) еллар буенча һәм аның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 1. Программа чараларын гамәлгә ашыру 2027 елга мөмкинлек бирәчәк:<br>1 кешегә исәпләгәндә хезмәтне саклау чараларына чыгымнарны 12000 сумга кадәр арттырырга; 1000 эшләүчегә исәпләгәндә җитештерүдә зыян күрүчеләр санын 1000 эшләүчегә 1,0 кешегә кадәр киметергә;<br>Эш урыннарын махсус бәяләүне һәм оешма җитәкчеләрен һәм белгечләрен хезмәтне саклау буенча укыту үткәрү.<br>2. Социаль нәтиҗә:<br>производствода бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар куркынычын киметү; җитештерүдә имгәнүләр һәм һөнәри авырулар дәрәҗәсен киметү; зарарлы һәм куркыныч җитештерү факторлары йогынтысыннан хезмәткәрләрне яклау дәрәҗәсен арттыру; имин булмаган хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләр санын кыскарту.<br>3. Социаль-икътисадый нәтиҗә:<br>производствода бәхетсезлек очракларыннан, җитештерү белән бәйле авырулардан, һөнәри авырулардан зыян күргән хезмәткәрләрнең сәламәтлеген торгызуга матди чыгымнарны киметү; производствода бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар нәтиҗәсендә хезмәткәрләргә китерелгән зыянны каплауга чыгымнарны киметү; хезмәтнең зарарлы һәм куркыныч шартларында, авыр хезмәт шартлары булган эш өчен ташламалар һәм компенсацияләр бирүгә чыгымнарны киметү;<br>моңа бәйле рәвештә производствода имгәнүләр яки һөнәри авыру һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә чыгымнар нәтиҗәсендә инвалидлык дәрәҗәсен киметү; эш вакыты югалтуларын кыскарту исәбенә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру;<br>имгәнүләр һәм җитештерү-бәйле авырулар аркасында төп хезмәткәрләрне алыштыра торган һәм эш һәм квалификация тәҗрибәсе булмаган вакытлы хезмәткәрләр тарафыннан ватылган җиһазларны ремонтлау һәм алмаштыру чыгымнарын кыскарту. |

## I. Хәл ителүенә озак сроклы территориаль программа юнәлдерелгән проблемага характеристика

Хезмәт саклау хезмәт эшчәнлеге барышында гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген саклауның мөһим шарты булып тора. Хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт идарәсе системасы хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга, хезмәт чорында кешенең иминлеген, сәламәтлеген һәм эшкә сәләтлелеген тәэмин итү буенча хокукый, социаль-икътисадый, оештыру-техник, санитария-гигиена, дәвалау-профилактика һәм башка чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән.

Биектау муниципаль районында хезмәтне саклау дәүләт идарәсе Россия Федерациясе Конституциясенең, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының тиешле закон һәм башка норматив актларының тиешле нормалары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Хезмәтне саклау белән идарә итү системасында Хезмәтне саклау буенча координация советына (алга таба - Совет) аерым бер роль бирелә, аның аша бу өлкәдә мөһим карарлар кабул ителә. Совет Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Хезмәтне саклау буенча Координацион Совет төзү турында»2018 елның 19 июлендәге 741 номерлы карары белән төзелде.

2023 елда Советның егерме бер утырышы үткәрелде, аларда хезмәткәрләрне индивидуаль яклау чаралары белән тәэмин итү, мәҗбүри медицина тикшерүе уздыру, мәгариф учреждениеләрендә хезмәтне саклау нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәү, чәчү һәм урып-җыю эшләрендә авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә хезмәтне саклауның һәм шартларының торышы, район предприятиеләрендә һәм оешмаларында хезмәтне саклау белән идарә итү системасын кертү, эш урыннары хезмәт шартларын махсус бәяләү мәсьәләләре каралды, предприятиеләрдә имгәнүләрне профилактикалауга аерым игътибар бирелә. Совет эше практикасында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча территориаль программа эшләү һәм кабул итү, производствода үлем очракларын, авыр нәтиҗәле бәхетсезлек очракларына юл куйган, җитештерү травматизмы югары булган предприятие җитәкчеләрен тыңлау.

Биектау муниципаль районында хезмәтне саклау белән идарә итү системасын булдыру буенча максатчан эш алып барыла. Эшләүче гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген саклау проблемаларын хәл итү бу юнәлештә эшне оештырудан башка мөмкин түгел. 2023 елда район предприятиеләрендә һәм оешмаларында хезмәтне

саклау белән идарә итү системасын булдыру эше алып барылды.

Биектау районында дәүләт статистикасы бүлеге мәгълүматлары буенча, җитештерүдә хезмәткә сәләтне югалту белән бәхетсезлек очраклары 2022-2023 елларда булмаган.

Производствода бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә зарар күрүчеләрнең абсолют һәм чагыштырма саны динамикасы 1 нче таблицада күрсәтелгән.

1 нче таблица

Биектау муниципаль районында җитештерүдә имгәнүләр динамикасы (Биектау районында дәүләт статистикасы бүлеге мәгълүматлары)

| **1 эш көненә һәм аннан да күбрәккә хезмәткә сәләтләрен югалткан һәм үлемгә китергән зыян күрүчеләр саны** | **2022** | **2023** |
|---|---|---|
| ***Барысы (шул исәптән хатын-кызлар)*** | 0 | 0 |
| Шулардан үлемгә китергән (шул исәптән хатын-кызлар) | - | - |
| **1 000 эшләүчегә исәпләгәндә**, барысы (шул исәптән хатын-кызлар) | - | - |
| шулардан үлемгә китергән (шул исәптән хатын-кызлар): | - | - |

2023 ел нәтиҗәләре буенча санитария-гигиена нормаларына җавап бирмәгән шартларда эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма саны 45.3 процент тәшкил иткән, шуларның 36.5 проценты хатын-кызлар.

2023 ел нәтиҗәләре буенча хезмәт шартлары торышын анализлау, санитария-гигиена нормативларына җавап бирмәгән шартларда эшләүче хезмәткәрләр саны түбәндәге нигездә башкарылды:

Биектау районындагы дәүләт статистикасы бүлеге мәгълүматлары;

1-Т номерлы федераль форма буенча предприятиеләрнең беренчел хисаплылык базасы (хезмәт шартлары).

Уздырылган анализ нәтиҗәләре буенча «санитария-гигиена нормаларына җавап бирмәгән хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең чагыштырма күләме» күрсәткече үсеше, шулай ук аның тотрыклы югары дәрәҗәсе предприятиеләрдә хезмәт шартлары һәм аның нәтиҗәләре буенча эш урыннары аттестациясен үткәрү белән бәйле.

Хезмәт шартлары буенча эш урыннарын махсус бәяләү - сәламәт һәм имин хезмәт шартлары тудыруда өстенлекле юнәлешләрнең берсе. Бу эшнең төп элементлары эш урыннарында зарарлы һәм куркыныч факторларны ачыклау, аларның факттагы күрсәткечләрен бәяләү. Алар тиешле нормативларга туры килмәгән очракта, хезмәт шартларын яхшыртуга, зарарлы һәм (яисә) куркыныч

хезмәт шартларында эшләү өчен ташламалар һәм компенсацияләр бирүгә юнәлдерелгән чараларны мәҗбүри планлаштыру таләп ителә.

Хезмәт шартлары буенча эш урыннарын махсус бәяләүнең нәтиҗәлелеген анализлау һәм бәяләү максатларында район предприятиеләрендә 1 нче номер - хезмәтне саклау формасы буенча «Производствода хезмәтне саклау турында белешмәләр» дигән еллык статистик күзәтү үткәрелә.

Хезмәтне саклау буенча ел саен укулар уздырганда, эш урыннарында хезмәт шартларын сыйфатлы һәм объектив бәяләү өчен махсус бәяләү уздыруны мәсьәләләренә оешма җитәкчеләрен һәм белгечләрен әзерләүгә аерым игътибар бирелә.

Хезмәтне саклауга дәүләт идарәсе системасын үстерү - якындагы елларга Биектау муниципаль районы җитәкчелегенең мөһим бурычларыннан берсе, аны хәл итү социаль-икътисадый сәясәт уздыруда һәм социаль партнерлыкны үстерүдә дәүләт идарәсенең барлык структуралары һәм дәрәҗәләре эшчәнлеген координацияләү аша мөмкин. Социаль партнерлык формаларының берсе - районның күп предприятиеләрендә һәм оешмаларында кискен проблемаларны хәл итүгә юнәлтелгән чараларны һәм икътисадый мөмкинлекләрне исәпкә алып, хезмәтне саклау буенча конкрет йөкләмәләрне күздә тоткан килешүләр һәм күмәк шартнамәләр төзү. Хезмәтне саклауга бирелә торган суммага хезмәткәрләрнең хезмәт иминлеге, аларның тормышы һәм сәламәтлеге турыдан-туры бәйле. Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 226 статьясы нигезендә хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау чараларын финанслау эш бирүченең бурычы булып тора, әмма үз хезмәткәрләренең иминлеге өчен социаль җаваплылык дәрәҗәсе түбән булган җитәкчеләр бу мәсьәләгә тиешле игътибар бирми. Хезмәтне саклау чараларына чыгымнар предприятиеләр җитәкчеләренең хезмәтне саклауга һәм үз хезмәткәрләренең гомерен һәм сәламәтлеген яклауга, димәк, хезмәтне саклау белән идарә итүнең гамәлдәге системасы нәтиҗәлелегенә карата мөнәсәбәтләренең яхшы индикаторы булып тора.

Биектау районында дәүләт статистикасы бүлеге мәгълүматлары буенча, 2023 елда район предприятиеләрендә хезмәтне саклау чараларына чыгымнар 37242,1 мең сум тәшкил иткән, яисә 1 эшләүчегә исәпләгәндә - 11494,47 сум, бу 2022 елга караганда 40,27 процентка күбрәк, ул вакытта 1 кешегә 8194,56 сум туры килгән.

2 нче таблица

Биектау муниципаль районында хезмәтне саклауга чыгымнар (Биектау районында дәүләт статистикасы бүлеге мәгълүматлары)

| **2022 ел** | | **2023 ел** | |
|---|---|---|---|
| барлыгы, мең сум | 1 эшләүчегә исәпләгәндә, сум | барлыгы, мең сум | 1 эшләүчегә исәпләгәндә, сум |
| 27312,5 | 8194,56 | 37242,1 | 11494,47 |

Хезмәтне саклау өлкәсендә иң массакүләм хокук бозу булып хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне өйрәтү һәм инструкция үткәрмәү кала. Оешмалар җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәтне саклау өлкәсендә җитәрлек дәрәҗәдә белеме булмау белән максималь табыш алу теләге кушылу производствода имгәнүнең сәбәбе булып тора.

Хезмәт өчен имин шартлар тудыру, травматизмны булдырмау кешеләрнең тормыш позицияләренә йогынты ясый торган эмоциональ халәт формалаштыру максатларында мәгълүматны, идеяләрне, фән һәм техниканың соңгы казанышлары турында белешмәләрне таратуга юнәлдерелгән хезмәтне саклауны оешкан мәгълүмати тәэмин итүгә һәм пропагандалауга турыдан-туры бәйле. Хезмәтне саклау мәсьәләләрен пропагандалау ысулларының күптөрлелеге булганда, ахыргы максаты - эшләүчеләрдә эшләрне имин уздыру таләпләрен аңлы үтәүнең кирәклеген тәрбияләү, хезмәткәрләрдә куркынычсыз эшкә ярдәм итә торган сыйфатларны үстерү, куркынычсызлык мәсьәләләренә уңай мөнәсәбәт тудыру. Статистик мәгълүматларга анализ күрсәткәнчә, оештыру сәбәпләре буенча травматизм техник сәбәпләр аркасында булган бәхетсезлек очраклары санынннан артып китә. Пропаганданың төп формасы булып нигездә халык алдында лекторларның җитәкчеләр, белгечләр һәм эшчеләр алдында лекцияләр, семинарлар, киңәшмәләр, белгечләр белән очрашулар, смотр-конкурслар һ.б. кебек формаларны кулланып, хезмәт куркынычсызлыгы тематикасы буенча чыгышлары тора. Район предприятиеләрендә ел саен иминлек һәм хезмәтне саклау айлыклары игълан ителә.

Массакүләм мәгълүмат чараларында хезмәтне саклау мәсьәләләрен яктырту хезмәт иминлеген пропагандалауның мөһим чаралары булып тора. Районның хезмәтне саклау буенча эш бирүчеләр һәм белгечләр арасында хезмәтне саклау буенча мәгълүмати-аналитик бюллетеньнәр зур популярлык казанды.

Хезмәтне саклау мәсьәләләрен мәгълүмати тәэмин итү һәм пропагандалау чаралары хезмәтне саклау таләпләрен үтәү өчен эшләүчеләрнең җаваплылыгын арттыруга ярдәм итә, бу җитештерүдә гомуми травматизмны киметүгә китерә.

Һәр өч ел саен Совет тарафыннан хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча район программасы кабул ителә, аны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә әлеге өлкәдә билгеле бер уңай үзгәрешләргә ирешелде.

Югарыда бәян ителгәннәр районда хезмәтне саклау проблемаларын хәл итүнең программа методын дәвам итүнең нәтиҗәлелеген һәм кирәклеген раслый.

## II. Программаның максаты һәм төп бурычлары, аны гамәлгә ашыру сроклары, Программа нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

2.1. Программаның максаты - Биектау муниципаль районы территориясендә

урнашкан оешмалар хезмәткәрләренең һөнәри куркынычларын киметү максатларында хезмәт шартларын һәм аны саклауны яхшырту.

2.2. Программаның төп бурычлары.

2.2.1. Хезмәтне саклау буенча дәүләт идарәсе системасын үстерү;

2.2.2. Укытуның заманча технологияләре нигезендә хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне өзлексез әзерләү;

2.2.3. Хезмәтне саклауны мәгълүмати тәэмин итү һәм пропагандалау.

2.3. Программаның максатлары һәм бурычлары буенча нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары. Куелган бурычларны хәл итүнең нәтиҗәлелеге түбәндәге индикаторларның күрсәткечләренә ирешүдә чагыла:

2.3.1. Хезмәтне саклау буенча дәүләт идарәсе системасын үстерү. Мәсьәләне чишүнең нәтиҗәсе булып «1 кешегә исәпләгәндә хезмәтне саклау чараларына чыгымнар» индикаторы күрсәткеченә - 12000 сумга кадәр ирешү тора;

2.3.2. Заманча укыту технологияләре нигезендә хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне өзлексез әзерләү.

2.3.3. Хезмәтне саклауны мәгълүмати тәэмин итү һәм пропагандалау.

Мәсьәләне чишүнең нәтиҗәсе булып «1000 эшләүчегә исәпләгәндә җитештерүдә зыян күрүчеләр саны» индикаторы күрсәткеченә - 1000 эшләүчегә 1,0 кешегә кадәр ирешү тора.

2.4. Программаны гамәлгә ашыру сроклары - 2025-2027 еллар.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны финанслау Биектау муниципаль районы предприятиеләре һәм оешмаларыннан бюджеттан тыш акчалар исәбеннән гамәлгә ашырылачак, гомуми күләмдә – 45000,0 мең сум, шул исәптән:

2025 елда - 15000,0 мең сум;

2026 елда - 15000,0 мең сум;

2027 елда - 15000,0 мең сум.

## IV. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаны гамәлгә ашыру белән идарә итүне Биектау муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы Хезмәтне саклау буенча координация советы гамәлгә ашыра.

Хезмәтне саклау буенча координация советы:

программа чаралары исемлеген, Программа чаралары буенча чыгымнарны һәм Программаны гамәлгә ашыру механизмын әзерләү һәм төгәлләштерү эшчәнлеген координацияли;

максатчан индикаторлар һәм Программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре исемлеген төгәлләштерә;

Программаны гамәлгә ашыруның барышы турында хисап алып бара һәм аны Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрә.

## V. Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

Биектау муниципаль районы предприятиеләре һәм оешмалары бюджеты чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү өч төп юнәлеш буенча алып барыла: потенциаль икътисадый нәтиҗәлелек, нәтиҗәләргә ирешүнең нәтиҗәлелеге, социаль-икътисадый нәтиҗәлелек.

Чыгымнарның потенциаль икътисадый нәтиҗәлелеге Программаны гамәлгә ашыруга тотылган чыгымнарга Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә җыелган зыянның суммаларына карата нисбәте буларак билгеләнә.

Нәтиҗәләрнең нәтиҗәлелеге халыкның тормыш сыйфатын бәяләү индикаторларының иң чик күрсәткечләренә ирешү белән билгеләнә:

1 кешегә 12000 сумга кадәр исәпләгәндә хезмәтне саклау чараларына чыгымнарны арттыру;

1000 эшләүчегә производство травматизмы дәрәҗәсен 1,0 кадәр киметү.

Программаның оциаль-икътисадый нәтиҗәлелеге түбәндәге күрсәткечләр белән бәяләнә:

производствода бәхетсезлек очракларыннан, җитештерү белән бәйле авырулардан, һөнәри авырулардан зыян күргән хезмәткәрләрнең сәламәтлеген торгызуга матди чыгымнарны киметү;

производствода бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар нәтиҗәсендә хезмәткәрләргә китерелгән зыянны каплауга чыгымнарны киметү;

хезмәтнең зарарлы һәм куркыныч шартларында, авыр хезмәт шартлары булган эш өчен ташламалар һәм компенсацияләр бирүгә чыгымнарны киметү;

моңа бәйле рәвештә производствода имгәнүләр яки һөнәри авыру һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә чыгымнар нәтиҗәсендә инвалидлык дәрәҗәсен киметү;

эш вакыты югалтуларын кыскарту исәбенә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру;

имгәнүләр һәм җитештерү-бәйле авырулар аркасында төп хезмәткәрләрне алыштыра торган һәм эш һәм квалификация тәҗрибәсе булмаган вакытлы хезмәткәрләр тарафыннан ватылган җиһазларны ремонтлау һәм алмаштыру чыгымнарын кыскарту.